**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл жирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2020 ел №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, **карар итәм**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2020 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2020 елның 13 ноябрендә 11.30 сәгатькә билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2021 елда Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 Төркем

инвалидларыннан 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;

2) Сарлы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Сарлы авылында "Сабантуй" бәйрәмен оештыру һәм уздыру;

4) татар милли киемнәре сатып алу;

5) Сарлы авылына керә торган юлны ремонтлау (вак таш ташу, вак таш җәю, юлларны тигезләү, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Сарлы авылы, Үзәк урамы, 68А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Р.Шарипов